ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Экология кодексының 45 статьясына һәм «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексының 45 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 86 (I өлеш); 2024, № 16 (I өлеш), № 47 (I өлеш); 2025, № 18 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«45 статья. **Региональ дәүләт экология контроле (күзәтчелеге)**

1. Региональ дәүләт экология контроле (күзәтчелеге), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Әгәр мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (куркынычсызлык мониторингы) барышында закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) килү яисә зарар (зыян) килү куркынычы барлыкка килү фактлары, мәҗбүри таләпләрне бозулар турында, әзерләнә торган мәҗбүри таләпләрне бозулар яисә мәҗбүри таләпләрне бозулар билгеләре турында белешмәләр ачыкланса, региональ дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) органы тарафыннан «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы

2 өлешенең 1 пунктында каралган тәртиптә әлеге ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирү хакында карар кабулителергә мөмкин.

3. Әгәр күчмә тикшерү кысаларында мәҗбүри таләпләрне бозулар билгеләре ачыкланса, региональ дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) органы тарафыннан «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктында каралган тәртиптә әлеге ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирү хакында карар кабул ителергә мөмкин.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 25 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 17 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2023, № 73 (I өлеш); 2024, № 76 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле 5 һәм 6 өлешләр өстәп, үзгәреш кертергә:

«5. Әгәр мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (куркынычсызлык мониторингы) барышында закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар (зыян) килү яисә зарар (зыян) килү куркынычы барлыкка килү фактлары, мәҗбүри таләпләрне бозулар турында, әзерләнә торган мәҗбүри таләпләрне бозулар яисә мәҗбүри таләпләрне бозулар билгеләре турында белешмәләр ачыкланса, Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органы тарафыннан «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктында каралган тәртиптә әлеге ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирү хакында карар кабул ителергә мөмкин.

6. Әгәр күчмә тикшерү кысаларында мәҗбүри таләпләрне бозулар билгеләре ачыкланса, Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органы тарафыннан «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктында каралган тәртиптә әлеге ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирү хакында карар кабул ителергә мөмкин.».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 03 октябрь
№ 67-ТРЗ

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ